СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.12.2021 Баулы шәһәре № 97

2022 елга Баулы муниципаль районы
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның
фаразлау планы (программасы) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елга Баулы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) расларга (1нче кушымта).

2. Әлеге карар аңа кул куйган вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы, район Советы
Рәисе вазыйфаларын башкаручы –
район башлыгы урынбасары, Советы
Рәисе урынбасары Р.Г. Хәмидуллин

Баулы муниципаль районы
Советының 2021 елның 14
декабрендәге
97 номерлы карарына
1нче кушымта

2022 елга Баулы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2022 елга Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә эшләнгән.

1.2. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Баулы муниципаль районы милкенең структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, район бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән.

1.3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2016 елның 13 августындагы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 66 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2.1. Баулы муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. Хосусыйлаштыру үткәрелмәгән, 2021 елга Баулы муниципаль районын хосусыйлаштыруның Фараз планына (программасына) кертелгән объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.3. Муниципаль милектәге муниципаль казна предприятиеләрен һәм акцияләрен 2022 елда хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

2.4. Хосусыйлаштыруның фараз планы гамәлдә булган чорда 2022 елда хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль мөлкәт исемлеге яңа күчемсез милек объектлары белән тулыландырырга мөмкин.

2.5. 2022 елда муниципаль милек хосусыйлаштырылырга тиеш (1 нче таблица).

1нче таблица

| № п/п | Объект исеме | Урнашу урыны (Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы) |
|---|---|---|
| 1. | Гараж бинасы, 16:55:010104:1322:0123, S- 340,9 кв.м. | Республика Татарстан, Бавлинский муниципальный район, г.Бавлы, гараж ОРСа |
| 2. | Җир участогы, 16:55:010104:1322, S- 2766,0 кв.м. | Республика Татарстан, Бавлинский муниципальный район, г.Бавлы, гараж ОРСа |
| 3 | 16:55:010308:56 кадастр номерлы торак булмаган бина- запас частьләр склады, гомуми мәйданы 466,6 кв.м. | ТР, Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |
| 4 | Җир участогы, гомуми мәйданы 24 970,0 кв.м., кадастр номеры номером 16:55:010308:69 | ТР, Баулы шәһәре, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Промзона |